«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
__________ А.Х. Гыйльметдинов
"20" гыйнвар 2012 нче ел

# Татар телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең IX сыйныф укучыларына 2012 нче елда ТАТАР ТЕЛЕННӘН яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен контроль бәяләү материалларының күрсәтмә варианты

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

**Татар телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең IX сыйныф укучыларына 2012 нче елда ТАТАР ТЕЛЕННӘН яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен контроль бәяләү материалларының күрсәтмә варианты**

## 2012 нче елда татар теленнән яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен контроль бәяләү материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар

2012 нче елда татар теленнән яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен контроль бәяләү материалларының күрсәтмә варианты белән танышканда, шуны истә тотыгыз: тәкъдим ителгән биремнәр 2012 нче елда контроль бәяләү материалларының вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын чагылдырмыйлар. 2012 нче елда татар теленнән яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе имтихан эшендә тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге татар теленнән төп гомуми белем бирү программаларын үзләштергән чыгарылыш сыйныф укучыларына 2012 нче елда яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант чыгарылыш имтиханы тапшыручыларга һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак контроль бәяләү материалларының структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында гомуми күзаллау бирә. Бу варианттагы киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрне үтәүнең бәяләү критерийлары киңәйтелгән җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Бу мәгълүматлар чыгарылыш сыйныф укучыларында яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясенә әзерлек осталыгын булдырачак.

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН
## яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Имтихан өчен 4 сәгать (240 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән тора (С1). Анда 2 тапкыр **тыңланган** текстның кыскача эчтәлеге (изложение) языла. Ул аерым биттә эшләнә.

**Икенче бүлек** укучылар **үзләре укыган** текстка нигезләнеп башкарыла. А1-А7 биремнәрендә тәкъдим ителгән 4 варианттан бер дөрес җавапны сайлап, имтихан эшендә түгәрәк тамгасы белән билгеләргә кирәк. Әгәр кирәкле номерны дөрес билгеләмәсәгез, түгәрәкләнгән номерны сызыгыз, шуннан соң дөрес җавапны түгәрәкләгез.

В1-В9 биремнәренә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга кирәк.

Әлеге бирәмнәргә җаваплар имтихан эшенең күрсәтелгән урыннарына сүз (сүзтезмә) яки сан белән языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга кирәк.

**Өченче бүлектә** укучылар 2 нче бүлектәге текст белән эшлиләр. Җавапларны С2 бланкына язалар. Бу эш укучылардан ныклап уйлауны, үз фикереңне дәлилләп, эзлекле итеп яза белүне таләп итә.

Имтиханда орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне эшләгәндә, караламадан файдаланырга мөмкин, әмма андагы язулар имтихан эшенә билге куйганда исәпкә алынмый.

Биремнәрне бирелгән тәртиптә үтәргә киңәш ителә. Аларны үтәү барышында кыенлык туса, биремне калдырып торып, алдагысына күчегез. Вакыт калган очракта, бу биремнәргә кабат әйләнеп кайту мөмкинлеге бар.

Балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

**Уңышлар телибез !**

## 1 нче бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм С1 биремен 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**С1** *Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.*

Текстны тыңлагач, микротемаларны (мәгънәви кисәкләрне) билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме 70 сүздән ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм тanырлык итеп языгыз.

(Текст 9 нчы биттә бирелә).

## 2 нче бүлек

***Текстны укыгыз һәм А1-А7; В1-В9; С2 биремнәрен үтәгез.***

### Имән

1) Борынгы Рим халкы имәнгә «кверкус» — «матур агач» дигән. 2) Чынлап та, күркәм, матур һәм нык агач ул. 3) Ирнең асылын имәнгә охшаталар: имән кебек нык диләр.

4) Безнең авыл янындагы тугай уртасында пәһлеван бер имән үсә. 5) Авылның түбән очыннан ук күренә, Алып батыр диярсең! 6) Үзен ник бер агач ышыкласын, үзе җил-давылга да бирешми. 7) Җәй коры килсә дә, әллә ни исе китми. 8) Дымны әллә кай тирәнлектән ала ул: күп санлы тамыр-тармакларын тирән җибәргән. 9) Тугайны язын су баса, ә ул суда утыра, кечерәеп калган кебек күренә. 10) Ә инде су киткәч, бөтен горурлыгы белән калкып чыга...

11) Имән өч йөз яшькә тикле чәчәк ата. 12) Егерме-утыз яшеннән үк башлый да ел саен армый-талмый чәчәк ата. 13) Үзе биш йөзне, меңне тутыра, хәтта ике меңне тутыра. 14) Йөз егерме-йөз кырык яшьләрдә буйга үсеп туктый да шуннан инде юаная гына бара.

15) Имәннәр чикләвектән дә, яшь үрентеләр җибәреп тә үрчи. 16) Әле күптән түгел генә тугайда икенчесе бар иде. 17) Шул яшь имәнне яшен уты күпсенде: буйдан-буйга көйдереп, яндырып төште дә бер тере мәет итеп калдырды. 18) Аны төптән үк кисми нишлисең? 19) Ләкин күпмедер вакыт үтүгә, төбеннән яшь-яшь үрентеләр күренде. 20) Эш бит менә нәрсәдә. 21) Элек зур печән кибәненә охшап торган имәннең, күп санлы юан ботакларындагы кебек үк, бөреләр төбендә дә булганнар. 22) Имән ел саен юанлыкка үскән дә гел өскә үрләгән, ә алар йокы симерткән. 23) Һәртөрле сайрар кошлар ыгы-зыгы килсә дә, кул яссуыдай киң-киң яфраклары, күп санлы ботак-тармаклары шаулап торса да, берсе бер колакларына да элмәгән:

изрәп йоклый биргән бөреләр. 24) Ләкин йокы аралаш кыймылдаша биргән алар.

25) Ә менә имәнгә хәвеф килгәч, аның тамырлары яшәрткеч дымны өскә күтәрде һәм бетмәс бер ташкын юан төп эчендә йоклап яткан бөреләргә ургылды, аларны борчыды, уятып җибәрде. 26) Моңарчы йокымсырап яткан бөреләр хәзер инде яшь үрентеләр булып тышка бәреп чыктылар һәм, күп тә үтмәде, яңа яшь яфраклар җыры башланды.

27) Карт имәннең тормышы дәвам итә...

*Гарәфи Хәсәнов буенча.*

***А1-А7 биремнәрен укыган текстның эчтәлеген истә тотып үтәгез. Аларның һәрберсенә бирелгән 4 җавап вариантының берсен – дөресен генә түгәрәкләп алыгыз.***

**А1** 3 нче җөмләдә **асыл** сүзе нинди мәгънәдә кулланылганын билгеләгез.

1) әйбернең төп сыйфатын күрсәтә;
2) нәрсәнең дә булса нигезен аңлата;
3) затлы ефәк тукыманы белдерә;
4) яхшы, менә дигән кеше мәгънәсендә кулланылган.

**А2** Җөмләдә аерып күрсәтелгән сүзнең **антонимын** табыгыз.

*Элек **зур** печән кибәненә охшап торган имәннең, күп санлы ботакларындагы кебек үк, бөреләр төбендә дә булганнар.*

1) дәү;
2) кечкенә;
3) юан;
4) киң.

**А3** Кайсы җөмләдә образ тудыру, сөйләмнең тәэсир итү көчен арттыру өчен, **мәгънәдәш сүзләр** кулланылган?

1) Безнең авыл янындагы тугай уртасында пәһлеван бер имән үсә.
2) Авылның түбән очыннан ук күренә, Алып батыр диярсең!
3) Чынлап та, күркәм, матур һәм нык агач ул.
4) Җәй коры килсә дә, әллә ни исе китми.

**А4** *“Борынгы Рим халкы имәнгә “кверкус” – “матур агач” дигән”* җөмләсендә **сызык** ни өчен куелган?

1) аныкланмышы исем белән белдерелгән аныклагыч алдыннан;
2) кискен каршы куюны белдергән тиңдәш кисәкләр арасына;
3) хәбәре исем белән белдерелгән җөмләдә ия белән хәбәр арасына;
4) хәбәре әйтелмәгән ким җөмләнең пауза ясалган урынында.

**A5** Текстның язылу **стилен** күрсәтегез.
1) хатлар стиле;
2) рәсми эш стиле;
3) публицистик стиль;
4) фәнни стиль.

**A6** 16-19 нчы җөмләләр арасыннан **иярченле кушма җөмләне** табыгыз.
1) 17;
2) 19;
3) 16;
4) 18.

**A7** 12-15 нче җөмләләрнең кайсысы **алгы рәт сузыклары гына** булган сүзләрдән төзелгән?
1) 12;
2) 13;
3) 15;
4) 14.

***B1-B9 биремнәрен укылган текст нигезендә үтәгез. Әлеге биремнәрнең җавабын тиешле урынга сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән языгыз.***

**B1** 6-8 нче җөмләләрдән **ирен гармониясенә буйсынган** сүзне табыгыз.

Җавап: ________________ .

**B2** 8 нче җөмләдәге **төшем килешендәге** ничә сүз бар?

Җавап: ________________ .

**B3** 24 нче җөмләдән **әйтелеше язылышына туры килмәгән** сүзне языгыз.

Җавап: ________________ .

**B4** 23 нче җөмләдән “ишетмәгән ” яки “тыңламаган” мәгънәсенә туры килгән **фразеологизмны** языгыз.

Җавап: ________________ .

**B5** **Тиңдәш кисәкләр янында** куелган тыныш билгесенең санын языгыз.
*Борынгы Рим халкы имәнгә «кверкус» (1)- (2) «матур агач» (3) дигән. (4)Чынлап та, (5) күркәм, (6)матур һәм нык агач ул.(7) Ирнең асылын имәнгә охшаталар: (8) имән кебек нык диләр. (9)*

Җавап: ________________ .

**B6** 19-21 нче җөмләләрдән **синтетик иярчен вакыт җөмләле кушма җөмләнең** номерын языгыз.

Җавап: ________________ .

**B7** 8-10 нчы җөмләләрдән **ясагыч кушымча ялгану ысулы белән ясалган рәвешне** языгыз.

Җавап: ________________ .

**B8** 17-19 нчы җөмләләрдән **билгесезлек алмашлыгын** языгыз.

Җавап: ________________ .

**B9** 8-10 нчы җөмләләрдән **билгесез үткән заман хикәя фигыльне** языгыз.

Җавап: ________________ .

***2 нче бүлек биремнәренә (А һәм В тибындагы) җавапларыгызны 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз!***

## 3 нче бүлек

***2 нче бүлектә бирелгән текстны файдаланып, С2 биремен үтәгез. Әлеге биремнең җавабын 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз. Яза башлар алдыннан биремнең номерын күрсәтегез.***

**С1**

**“Карт имәннең тормышы дәвам итә...”** җөмләсендә әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз?

Фикерегезнең дөреслеген раслау өчен, укылган тексттан 2 мисал китерегез. Бу вакытта файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **70 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## Татар теленнән имтихан эшен тикшерү һәм бәяләү системасы

### 1 нче бүлек

| Тыңлау өчен текст |
|---|

### Матурлык

Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Аяз күктән өстебезгә сихри бер моң өзлексез явып торды. Беләсезме тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Тургай сайраганда, җир өстенә җиңелчә тынлык җәелә. Барлык табигать, тын калып, бары аны гына тыңлый һәм сөенечле, сагышлы, ләззәтле рәхәткә чума... Икенче сихере шунда: тургай сайраганда, дөнья искиткеч, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе кебек, җир йөзе дә тын, нурлы булып тоела башлый...

Бу вакытта бүтән кошлар сайрыйдырмы, белмим. Бөтен дөнья тургайлар сайравыннан чыңлап торса да, бер кош тавышы колагыбызга килеп керә. Бу – кәккүк! Табигать тарафыннан яратылган күзгә күренмәс сәер кош!.. Күксел урман яныннан узганда, без аның кисәтүле тавышын ишеттек.

Шулай кайта торгач, без үзәнлектә сузылып утырган Ишле авылына якынлаштык. Бәдретдин безне чәй эчәргә чакырган иде. Без кыстатып тормадык. Иптәшеңә кереп, чәй эчеп чыгу шәкертләр өчен табигый бер тәртип, кагыйдә инде ул. (137 сүз)

Әмирхан Еники буенча.

### Кыска изложениене (С1 биремен) тикшерү һәм бәяләү

*1 нче таблица*

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Безне тургайлар сайравы озатып барды. |
| 2 | Кәккүк – күзгә күренмәс сәер бер кош! |
| 3 | Бәдретдиннең чакыруы шәкертләр өчен табигый бер тәртип, кагыйдә ул. |

*2 нче таблица*

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1**[1] | **Изложение эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган, әмма бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган, әмма бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 0 |
| **ИК2** | **Башлангыч текстны җыйнакландыру** | |
| | Укучы текстның гомуми эчтәлеген бер яки берничә алым белән кыскарткан, җыйнакландырган | 3 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның ике микротемасы җыйнакландырылган | 2 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның бер микротемасы җыйнакландырылган | 1 |
| | Текстны җыйнакландыру өчен бер алым да **кулланылмаган** | 0 |
| **ИК3** | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>-логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>-текст кызыл юлларга дөрес бүленгән | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма**<br>бер логик хата бар<br>**яки**<br>кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма**<br>бердән артык логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 0 |
| **ИК1-ИК3 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | **7** |

[1] Изложениене бәяләү өчен беренче критерий.

## 2 нче бүлек

### А1-А7, В1-В9 биремнәрен тикшерү һәм бәяләү

**Икенче бүлектәге** һәр биремгә (А1-А7; В1-В9) дөрес җавап биргән өчен, укучыга **берәр балл** куела. Җавап ялгыш булса яки бөтенләй булмаса, **0 балл** куела.

Икенче бүлектәге 16 тест биременә дөрес җавап биргән өчен укучы җыярга мөмкин булган **иң югары балл – 16.**

А1-А7 биремнәренең һәрберсенә **бер дөрес җавап билгеләнсә генә** бер балл куела. Әгәр түгәрәкләп билгеләнгән ике яки аннан да артык җаваплар эчендә дөресе дә булса, ялгыш җавап сызылмаса, бирем өчен балл куелмый.

*3 нче таблица*

| Бирем номеры | Дөрес җаваплар |
|---|---|
| А1 | 4 |
| А2 | 2 |
| А3 | 3 |
| А4 | 1 |
| А5 | 3 |
| А6 | 2 |
| А7 | 3 |

*4 нче таблица*

| | |
|---|---|
| В1 | коры |
| В2 | 2 |
| В3 | йокы |
| В4 | колакларына да элмәгән |
| В5 | 6 |
| В6 | 19 |
| В7 | язын |
| В8 | күпмедер |
| В9 | җибәргән |

## 3 нче бүлек

## С2 биремен тикшерү һәм бәяләү

*5 нче таблица*

| № | Текст эчтәлегенә анализ ясауга бәйле һәм фикерләү характерындагы сочинениене (С2 биремен) бәяләү тәртибе | Балл |
|---|---|---|
| **$C_2$К1**[2] | **Текстның мәгънәсен аңлау** | |
| | Укучы текстның мәгънәсен дөрес аңлаткан, хаталар күзәтелми | 2 |
| | Гомумән алганда, укучы текстның мәгънәсен дөрес аңлаткан, тик бер хата җибәргән | 1 |
| | Укучы текстның мәгънәсен дөрес аңлатмаган<br>**яки**<br>эчтәлеген аңлатканда  ике хата җибәргән<br>**яки**<br>имтихан эшендә текстның эчтәлегенә аңлатма бирмәгән | 0 |
| **$C_2$К2** | **Тексттан табылган мисалларның булуы** | |
| | Укучы тексттан анның эчтәлегенә туры килә торган ике мисал тапкан | 3 |
| | Укучы тексттан анның эчтәлегенә туры килә торган бер мисал тапкан | 2 |
| | Мисал(-лар) укылмаган башка бер тексттан китерелгән | 1 |
| | Укучы тексттан анның эчтәлегенә туры килә торган бер мисал  да тапмаган<br>**яки**<br>биремдәге цитата яки анның бер өлеше мисал итеп китерелгән | 0 |
| **$C_2$К3** | **Сочинениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм анның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм анның эзлеклелеге сакланган:<br>-логик хаталар күзәтелми, язганда эзлеклелек сакланган;<br>-текстны кызыл юлга бүлүдә хаталар юк | 2 |

[2] **С** бүлегендәге **икенче** биремне бәяләү өчен **беренче** критерий.

| | | |
|---|---|---|
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге сакланган,<br>**эмма**<br>бер логик хата җибәрелгән<br>**яки**<br>кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**эмма**<br>бердән артык логик хата **яки**<br>кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 0 |
| **$C_2$К4** | **Эшнең композицон төзеклеге** | |
| | Эш композицон яктан төзеклеге һәм төгәлләнгән булуы белән аерылып тора, текст төзелешендә хаталар юк | 2 |
| | Эш композицон яктан төзеклеге һәм төгәлләнгән,<br>**эмма**<br>текст төзелешендә бер хата бар | 1 |
| | Композицон яктан ике һәм аннан артык хата бар | 1 |
| **$C_2$К1-$C_2$К4 күрсәткечләре буенча сочинение өчен җыела торган иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Әгәр сочинение тулысынча күчереп язылган текстка туры килә икән, аңа бөтен критерийлар (**$C_2$К1-$C_2$К4; ГК1-ГК4, ФК1)** буенча да **0 балл** куела.

Укучының грамоталылыгы һәм язма сөйләменең төгәллеге изложение һәм сочинение тикшерү нәтиҗәсендә тупас һәм тупас булмаган яки төрле һәм бер үк типтагы хаталарны исәпкә алып бәяләнә.

*6 нчы таблица*

| № | Укучының грамоталылыгын һәм язма сөйләменең төгәллеген бәяләү | Балл |
|---|---|---|
| **ГК1**[3] | **Орфографик нормаларның үтәлүе** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** тупас булмаган бер хатасы бар | 2 |
| | Өч-дүрт хата җибәрелгән | 1 |
| | Биш һәм аннан артык хатасы бар | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** тупас булмаган ике хатасы бар | 2 |

[3] **Грамоталылыкны** бәяләү өчен **беренче** критерий.

| | | |
|---|---|---|
| | Өч-дүрт  хата җибәрелгән | 1 |
| | Биш һәм аннан артык хатасы бар | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** тупас булмаган бер хатасы бар | 2 |
| | Ике хата җибәрелгән | 1 |
| | Өч һәм аннан артык хатасы бар | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** тупас булмаган ике хатасы бар | 2 |
| | Өч-дүрт  хата җибәрелгән | 1 |
| | Биш һәм аннан артык хатасы бар | 0 |
| **ФК1**[4] | **Язма сөйләмнең төгәллеге** | |
| | Материалны язуда, шулай ук терминнарны аңлауда һәм куллануда фактик хаталар юк | 2 |
| | Язуда һәм терминнарны куллануда бер хата бар | 1 |
| | Язуда һәм терминнарны куллануда ике һәм аннан да артык хата бар | 0 |
| **ФК1, ГК1-ГК4 критерийлары буенча сочинение һәм изложение язган өчен җыярга мөмкин булган иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, (ГК1-ГК4) изложение һәм сочинениенең **күләме** исәпкә алына.

5 нче таблицада күрсәтелгән нормалар гомуми күләме 140 һәм аннан да артык сүз булган **изложение белән сочинениеләрне** тикшерү һәм бәяләү өчен файдаланыла. Аларның гомуми күләме 70-139 сүз булса, ГК1-ГК4 критерийларының һәрберсе өчен 1 балл куела:

ГК1- орфографик хаталары булмаса яки 1 тупас булмаган хата җибәрелсә, 1 балл куела.

ГК2 – пунктуацион хаталары булмаса яки 1 тупас булмаган хатасы булса, 1 балл куела.

ГК3 – грамматик хаталары булмаса, 1 балл куела.

ГК4 – сөйләм хаталары булмаса, 1 балл куела.

**Изложение белән сочинениенең** күләме 70 сүздән дә ким булган эшкә ГК1-ГК4 күрсәткечләре буенча 0 балл куела.

Укучы изложение белән сочинениенең **берсен генә** (я изложение, я сочинение) язган очракта, эшнең күләмен искә алып, ГК1-ГК4 күрсәткече буенча бәяләнә:

- эшнең күләме 140 сүздән ким булса, грамоталылык 6 нчы таблица буенча бәяләнә;

[4] **Фактик** хаталарны бәяләү өчен **беренче** критерий.

- эшнең күләме 70-139 сүз булса, ГК1-ГК4 күрсәткеченең һәрберсенә 1 балл куела (16 нчы битне карагыз);
- эшнең күләме 70 сүздән дә ким булса, ГК1-ГК4 күрсәткече буенча 0 балл куела.

Имтихан эше өчен җыярга мөмкин булган **иң югары балл – 42**.